ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.07.2019 ел Баулы шәһәре №195

Балигъ булмаган баланың
күчемле милеген бүтән затка
бирү буенча алыш-бирешләрне
гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт
бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән 210-ФЗ номерлы Федераль закон (2018 елның 29 июлендәге редакциядә) нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендә кабул ителгән 880нче номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы карарына (2018 елның 24 июлендәге редакциядә) таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы Балигъ булмаган баланың күчемле милеген бүтән затка бирү буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И.Гозәеров